وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№9 (126). 2 март 2012 / 9-раббигыль-ахир-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





Хаҗиларга дини, уңайлы һәм... милли кием кирәк ▷2◁





*К.НАСЫЙРИ* иҗатында татар халык тәрбиясе ▷3◁





Скопьеда кар мәчет барлыкка килде ▷4◁


## ЯҢАЛЫКЛАР

### ЧАҢГЫ ЯРЫШЛАРЫ ҮТТЕ

26 февраль көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте мөселман яшьләре арасында чаңгы ярышы уздырды.

Ярыш Казан шәһәренең 136 нчы мәктәбендә узды. Чарада Нурлат, Чистай, Ютазы, Яңа Чишмә, Буа, Әгерҗе, Мамадыш, Менделеевск, Зәй, Апас, Мөслим, Сарман, Азнакай районнары һәм Казан шәһәре спортчылары катнашты.

I урынны Россия ислам университетының әзерлек бүлеге студенты Самат Мөхлисов яулады. II урын Ислам дине кабул итүлүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсәнең IV курс шәкерте Марат Галиевка, III урын Яңа Чишмәдән килгән Салават Мөхлисовка бирелде.

Җиңүчеләргә диплом, медаль һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

### МАМАДЫШ РАЙОНЫНДА ЯҢА МӘЧЕТ ТӨЗЕЛӘЧӘК

27 февраль көнне Мамадыш районының Кызыл Тау авылында мәхәллә оештыру һәм мәчет салу уңаеннан җыелыш узды. Җыелышта авыл һәм район хакимияте вәкилләре, җирле имамнар һәм районның имам-мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миннегалиев катнашты.

"Мәчет төзелеше җирле эшкуар Радик Дамир улы Низамов ярдәме белән алып барылачак, - диде Илһам хәзрәт. - Авыл Советы мәчет өчен җир кишәрлеге бүлеп бирде. Хәзер төзелеш буенча әзерлек эшләре алып барыла, мәчет проекты төзелә. Яңа мәчеткә имам итеп Габдрахман хәзрәт Хәбибуллинны билгеләргә ниятлибез".

### УЛЬЯН ӨЛКӘСЕНДӘ АССОЦИАЦИЯ ФИЛИАЛЫ АЧЫЛДЫ

Мөселман эшкуарлары ассоциациясе Ульян өлкәсендә үзенең филиалын булдырды. Оештыру җыелышында ассоциация советы әгъзалары, Ульян өлкәсе губернаторының беренче урынбасары Вилдан Зиннуров, Ульян мөфтие Сәүбән хәзрәт Сөләйманов, "Болгар-Яңарыш" оешмасы советы рәисе Шәүкәт Богданов, "Биләр" мәдрәсәсе директоры Илдар Сафиуллин, Ульян өлкәсенең "Яңа дулкын" татар яшьләре берлеге рәисе Марат Хәйруллин, "Туган тел" оешмасы җитәкчелеге, милли-мәдәни диаспора вәкилләре, Ульян өлкәсе эшмәкәрләре катнашты.

Катнашучылар шулай ук филиалның максат һәм бурычларын билгеләде, җитәкче һәм шура әгъзалары сайлау буенча комиссия булдырды.

### МӨФТИ - ТӘТЕШТӘ

28 февраль көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз Тәтеш районының Тархан авылы халкы белән очрашты. Әлеге чарада имамнар, абыстайлар һәм авыл халкы катнашты. Очрашуга өч йөзләп кеше килгән. Шулай ук район хакимияте башлыгы Валерий Чершинцев, район имам-мөхтәсибе Инсаф хәзрәт Җәләлетдинов та булган.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# Ислам - тынычлык дине

**Дөнья гел үзгәреп тора. Иртәгә нәрсәләр буласын беркем дә әйтә алмый. Барысы да Аллаһы Тәгалә хозурында. Әле кайчан гына без Советлар Союзында яши идек, инде аның таркалуына да 20 ел вакыт узып китте. Чирек гасыр да үтмәде, дөньяда бик күп үзгәрешләр булды: конфликт-низаглар, революцияләр, иҗтимагый-сәяси системаларның тамырдан үзгәртелүе, берләшүләр...**



Дөньяның төрле нокталарында кискен үзгәрешләр барган вакытта аеруча мөһим урынны зур дәүләтләр алып барган халыкара сәясәт билгели. Төрле радикаль агымнарның вәкилләре нәрсә генә дисәләр дә, мөселманнар бу үзгәрешләрдән читтә кала алмый. Ләкин монда сүз шәхси сәяси максатларга ирешү турында бармый. Дөрес төзелгән халыкара мөнәсәбәтләр Ислам диненең дөньяга таралуына сәбәп булып тора. Моннан тыш, бу -мөселманнарны һөҗүм итүчеләр, агрессорлар буларак кабул итүне бетерүгә китерәчәк.

Соңгы 20 ел эчендә төрле террорчыл төркемнәр, ислам диненә ышыкланып, шул хәлгә китереп җиткерделәр ки, хәтта дөньяда мөселманнардан курка башладылар. Ислам - тынычлык дине. Кяферләргә каршы җиһадка бертуктаусыз чакырып торучылар ялгыша. Мөселманнарны бу, әлбәттә, яхшылыкка илтми. Кызганыч, кешеләр пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв) үзенең сәхабәләрен адашканнарга карата түзем булырга чакыруын оныта. Ислам динен күпсанлы дингә ышанмаучылар арасында таратыр өчен, пәйгамбәребезнең хикмәте нәкъ менә шул булган. Әгәр дә ул һәрвакыт көч кулланып торган булса, аңа ышанучылар булмас та иде. Пәйгамбәребезнең (сгв) сыйфатлары шулкадәр гүзәл булган ки, аның белән аралашып эш иткәннән соң, кешеләр ислам динен кабул иткән. Тик хәзер кискен караштa булучылар бу турыда оныта.

Бүгенге көндә без нәрсә күзәтәбез соң? Бер илдә манара күтәрергә рөхсәт итмиләр, икенчесендә - хиҗапны тыялар. Ләкин мөселманнар гаепне үзләреннән эзләргә тиеш. Дөньядагы бар телеканал мөселманнарның үз җитәкчеләре булган Муаммар Каддафиның үле гәүдәсен ничек мыскыл иткәнне күрсәтте. Шул да булдымы инде чын мөселманнар? Менә шундыйлар өчен мөселманнар аз яшәгән илләрдә шартлар тудырылырга тиешме? Беренче чиратта, мөселманнар, шул исәптән Россия мөселманнары да, дөньякүләм аудитория алдында мөселман образының нинди булуы турында уйланырга тиеш. Юк, бу рия булып саналмас. Бу - үзебезне күрсәтү өчен түгел, ә мөселманнарга карата ихтирам тудыру өчен.


Һичшиксез, дөньяда мөселманнар турында яхшы фикер урнашсын өчен, төрле террорчыл, экстремистик оешмалар, партияләр, төркемнәр алып килүче тискәре йогынтыны бетерергә кирәк. Бу шулай ук Россиягә дә кагыла. Кавказда XX гасырның туксанынчы елларында законсыз коралланган формированиеләр (бандформирование) оештырган сугыш әле дә булса дәвам итә. Әйе, хәзерге вакытта бу актив сугыш түгел инде. Ләкин Кавказ республикаларында, хәтта Мәскәүдә дә булган шартлаулар әле дә булса хәтердә. Казанда үтәчәк Универсиада, Сочида узачак Олимпиада алдыннан террорчылардан теләсә нинди адым көтәргә мөмкин...

Без ислам диненең Россия өчен чит булмавын, аның берәүгә дә көчләп тагылмавын күрсәтергә тиеш. Болгар дәүләте чорыннан ук бу җирләрдә пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв) сөннәте буенча яшәгәннәр, Коръән укыганнар, ислам дине кануннарын үтәгәннәр. Без тагын бер тапкыр Россиядәге мөселман өммәтенең чит илдән тәэмин ителеп торучы террорчылар түгеллеген, ә бәлки, укымышлы, төрле дәрәҗәдә сүз алып барырлык кешеләр булуын күрсәтергә тиешбез.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# "Гарәп язы" һәм интернет-технологияләр турында Путин ниләр яза?

**Илебезнең тышкы сәясәтенә атап язылган мәкаләсендә (27 февраль) РФ Президентына кандидат Владимир Путин, мөселман дөньясы вакыйгаларына, аерым алганда, "гарәп язы"на да зур игътибар биргән.**



- РФ Хөкүмәте рәисенең илебезнең алда торган бурычларын АКШ яисә Европа берлегеннән түгел, ә Якын Көнчыгыш һәм аннан килеп Азия төбәге конфликтларыннан бәян кыла башлавы - бик тә әһәмиятле, - дип саный тышкы сәясәтнең Герман советы каршындагы Россия һәм Евразия буенча үзәк директоры Александр Рар. "РФ Президенты вазифаларына кандидатның, АКШның омтылышлары Россия куркынычсызлыгы өчен иң зур "вызов" буларак, безнең көннәрдәге халыкара тәртипне Көнбатыш интереслары белән авазддаш булган хәлдә яңадан карарга кирәк дип белдергәнлеге күзаллана", - дип китерә эксперт сүзләрен РИА "Новости".

В.Путин үз мәкаләсендә билгеләп узганча, "бер ел элек Җир шары яңа феномен - күп кенә гарәп илләренең синхрон демонстрацияләр катнашында авторитар режимга каршы булуы белән очрашты".

""Гарәп язы", - дип яза премьер-министр, - иң башта позитив үзгәрешләргә өмет белән кабул ителде. Россиялеләрнең симпатиясе демократик реформаларга ирешергә тырышканнар ягында булды. Әмма тиздән күп кенә илләрдә вакыйгаларның цивилизацияле сценарий буенча юнәлеш алмаганлыгы ачыкланды. Демократияне беркетү, азчылыкның хокукларын яклау урынына - каршы якны этеп чыгару, кискен борылыш, бер көчнең өстенлек алуы аннан тагын да агрессиврак булганының өстен булуы белән алмашына барды".

Моннан тыш, РФ Хөкүмәте башлыгы шуңа да игътибар юнәлткән: әйтик, аннан соңгы кысылулар тышкы яктан эчке конфликтларның кайсы да булса берәр ягын яклауга һәм мондый тыкшынулардагы "силовой характер"лар үзе үк вакыйгалар үсешенә тискәре төсмер салды.

"Шуңа хәтле килеп җитте ки, күп кенә дәүләтләр гуманитар лозунглар янына ышыкланып авиация ярдәмендә Ливия режимы белән эшне тәмам кылды. Һәм апофеоз - Муаммар Каддафи белән чиркаңыч вакыйга хәтта урта гасырлардагыга да ошамаган, ә ниндидер кыргый үч алулар кебек", - дип әйтә Владимир Путин.

Мәкаләдә "гарәп язы"на җәлеп ителгән заманча информацион һәм коммуникацион технологияләр дә читләтеп үтелмәгән.

Шуны әйтергә мөмкин: Интернет, социаль челтәрләр, кесә телефоннары телевидение белән беррәттән һәм эчке, һәм халыкара сәясәттә нәтиҗәле инструментка әверелде. Бу акыл таләп итүче яңа фактор, аерым алганда, Интернетта эшне киң җәелдереп һәм андагы аралашуда уникаль ирек булдырып, аны террорчылар һәм җинаятьчеләр файдалана алудагы хәвеф-хәтәрне киметүдән гыйбарәттер.


*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Хаҗиларга дини, уңайлы һәм... милли кием кирәк

**Хаҗ - Исламда рухи һәм матди әзерлек таләп итә торган бишенче фарыз гамәл. Мөгаен, кемдер икенче бер кешенең хаҗга барырга рухи әзерлек дәрәҗәсен төгәл генә билгели алмас, ә менә матди якны чамаларга була. Әйтик, бүгенге көндә хаҗга ким дигәндә 70 мең сум акчасы булганнар бара ала, чөнки иң очсыз юллама бәясе шул чама тора, дип яза www.intertat.ru сайты.**



Матди як дигәндә, хаҗ кылырга җыенган кешенең юлына, анда баргач яшәренә, ашарына акчасы җитәрлек булу мөһим. Әлеге чыгымнар белән бергә кием мәсьәләсе дә баш калкыта. Хаҗилар изге сәфәр вакытында ничек киенә соң? Татарстан хаҗилары башкалардан аерыламы?

## Изге сәфәргә киендер!

ТР мөселманнары Диния нәзарәте карамагындагы Мөселман эшкуарлары ассоциациясе хаҗиларның өс киемнәренә кагылышлы мәсьәләләрне бизнесменнар, дизайнерлар ярдәмендә табарга уйлады. Төгәлрәге, алар Татарстан (татар дип әйтсәң дә дөрес булыр) хаҗиларының бердәм хаҗ киемен булдырырга ниятли. Шул нияттән, мөфтият хаҗ киеменә конкурс үткәрә. Ул ике этапта узачак. 20 мартка кадәр дизайнер-модельерлар хаҗ костюмнары эскизларын тәкъдим итәргә тиеш. Аннары апрель урталарына әлеге эскизлар буенча кием үрнәген тегәчәкләр.

Мөселман эшкуарлары ассоциациясе җитәкчесе Радик Гафуров сүзләренә караганда, җиңүчеләрне рухи кыйммәткә ия бүләк көтә. Шулай ук кием дизайнерының авторлык хокукы теркәләчәк һәм сатудан кергән керемнең билгеле бер өлеше аңа биреләчәк.

Хаҗи костюмнарына кагылышлы беренче утырышка ассоциация татар милли товарлары белән сәүдә итүче дистәләгән бизнесмен һәм дизайнерны җыйды. Аларның күбесендә хаҗ киеменә кагылышлы конкурс кызыксыну уяткан. Сөйләшүнең рәсми өлеше башланганчы ук, бу теманы үзара кызып китеп тикшерделәр, телефон номерлары алыштылар.

Яшь кенә булуына карамастан, мөселман киемнәре дизайнеры, Казан милли тикшеренү технология университеты (КНИТУ) студенткасы Энҗе Галәветдинованың хаҗ киемен тегү тәҗрибәсе бар икән инде. Үткән ел "Идел-хаҗ" оешмасы "Ниса" компаниясенә хаҗ киемнәрен тегәргә заказ биргән булган. Энҗе менә шул компания өчен хаҗ киеме эскизларын эшләгән.

"Узган ел "Идел-хаҗ" өчен җиде йөзләп хатын-кызга табигый тукымадан халат, туника, чалбар, ә ирләргә - күлмәк белән чалбар тегелде", - диде дизайнер. Бу юлы ул башка ателье исеменнән килгән. Конкурста катнашырга теләген яшермичә, инде күңелендә берничә төрле хаҗ киеме эскизы йөртүен дә әйтте.

Аның янәшәсендәге күн читекләр, милли бүләкләр җитештерүче "Гранд Мастер-Р" оешмасының хуҗабикәсе Регина Рәхмәтуллина исә хаҗиларга аяк киемнәре тегәргә кызыга. "Без инде өч ел читекләр, милли аяк киемнәре тегәбез. Алар бик уңайлы, көн дә кия торган итеп эшләнелә. Читекләребезне бик теләп алалар, чит илләргә алып китәләр. Күптән түгел Ирина ханым Миллерга ("Газпром" башлыгының хатыны - ред. искәрмәсе) бүләккә эшләттеләр. Менә хаҗиларга да аяк киемнәре тегеп карыйсыбыз килә, шуңа да бу очрашуга килдем", - диде ул. Моңа кадәр хаҗиларга махсус аяк киемнәре әзерләгәнебез юк иде. Шуңа күрә, читекчеләрдән яңа төр аяк киеме уйлап табу таләп ителмәсә дә, шактый үзенчәлекле эшләр башкару көтелә.

Эшкуарларның конкурста катнашырга теләкләре зур, әмма аларны хаҗ киемнәренә кагылышлы мәгълүмат булмау аптырашта калдырган. Сөйләшү барышында бизнесменнарның дини киемгә кагылышлы сорауларына Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз, Мөселман эшкуарлары ассоциациясе җитәкчесе Радик Гафуров һәм шулай ук очрашуда катнашкан башка хаҗилар җавап бирде. Шуларның кайберләренә тукталып үтәбез.

## Хаҗилар киеме конкурсы ни өчен үткәрелә?

Илдус хәзрәт Фәиз, иң беренче чиратта, эшкуарларны үзара итагать сакларга һәм бары тик Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен тырышырга чакырды. "Хаҗ кылу Исламда мәҗбүри һәм ул бик авыр башкарыла торган гамәл. Монда кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәте дә сынала. Хаҗга барганда, кеше бар нәрсәгә әзер булырга тиеш. Минем уйлавымча, Татарстан хаҗиларына әзерләнгән киемне башка төбәк татарларына да тәкъдим итәргә булыр", - диде ул.

Радик әфәнде: "Хаҗга әзерләнгәндә һәрвакыт: "Үзең белән нәрсә алырга? Нинди киемнәр кияргә?" - дигән гадәти сораулар борчый. Хаҗ кыла торган урыннарда табигать шартлары безнекеннән аерыла. Күп вакыт җәяүләп йөрергә туры килә. Төнлә исә чүлдә куналар, анда салкынча була. Шуңа күрә, хаҗи киеме шактый зур әһәмияткә ия. Башка илләрдән килүчеләр расланган бер төсле киемнәрдән йөри. Мәсәлән, төрекләрне алыйк. Беренчедән, ул күркәм күренә, икенчедән, бу - Төркия мөселманнарының бердәмлеген күрсәтә. Костюмнары милли үзенчәлекләрне кулланып, уңайлы итеп тегелгән. Башка илләрдән килүче хаҗиларның да үз киемнәре бар. Россиядә республикабыз Исламны кабул итү вакыты буенча да, аны таратуда да лидер, безгә хаҗиларыбызның бердәм хаҗ костюмы комплектын булдырырга вакыт җитте", - диде.

Хаҗ костюмы комплекты дигәндә, хатын-кызлар һәм ир-атлар күлмәге, чалбар, ихрам тукымасы, баш һәм аяк киеме, билбау, сумка, хәтта чүлдә ятып йоклар өчен җәймә дә күз алдында тотыла.

## Хаҗ киеме теккәндә нинди таләпләр куела?

"Хаҗи киеме ислам дине кануннарына туры килергә һәм шул ук вакытта аның бәясе дә кеше күтәрә алырлык булырга тиеш. Бу - бер җирдән килгәннәр бер-берсен ерактан ук шул киемнәре аша таный алсын өчен кирәк", - дип ассызыклады Илдус хәзрәт. Шулай ук, ул ир-атларның ихрам киемнәре энә-җеп белән тегелгән булмаска тиеш икәнлекне дә искәртте.

Радик әфәнде, үз чиратында, хаҗилар киемендә халкыбызның милли йөзен чагылдырырга чакырды. Бу уңайдан, татар милли бизәкләренә, Татарстан байрагына мөрәҗәгать итәргә була. Ә менә туграны дини киемгә төшерергә ярамый, чөнки анда барс - җәнлек рәсеме сурәтләнгән.

Әлбәттә, хаҗ кылу болай да очсыз тормый. Шуңа күрә кием бәясе күпләр өчен зур роль уйнарга мөмкин. Кайбер хаҗилар киемне ике вариантта: очсызрак һәм аннан бераз кыйммәтрәк булган тукымадан тегеп карарга киңәш итә. Шул ук вакытта, ул ясалма тукымадан тегелмәсә яхшы, чөнки хаҗга төрле яшьтәге кешеләр бара. Кием аларның сәламәтлегенә зыян китерерлек булырга тиеш түгел. Әле аның документларны, акчаларны караклардан, хаҗ кылу ыгы-зыгысында төшеп калып югалудан да саклавы зарур.

Очрашуда катнашкан хаҗиләр күлмәкләрнең җиңен төймә белән эләктермәле итмәскә, киң итеп тегәргә киңәш итте. Җиңне тәһарәт алганда һаман саен төймәләп тору читен диләр. Үткән ел хаҗга баруны оештырган бер туристик оператор саткан киемне ирләр, Мәккәгә баргач, кия алмаган. Чөнки намаз укыганда ул арттан ачылып китә торган итеп тегелгән. Моннан тыш, аның җиңе кыска булу да хаҗиларга ошап бетмәгән. "Татар ир-атлары, безнең бабайлар терсәктән төшеп торган җиңле күлмәк кигәннәр бит. Хаҗда ачык терсәкле күлмәк киеп йөрү урынсыз", - дип аңлатты моны хаҗилар.

**Айзирәк ГӘРӘЕВА**

# АЛЛАҺ РИЗА




**Әгүүзү билләәһи минәшшәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил галәмииин. Үәссаләәтү үәссәләәмү галәә расүүлинә мүхәммәдиү вә галәә әәлиһи вә әсъхабиһи әҗмәгыйн.**

Газиз дин кардәшләрем, әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллааһи вә бәракәәтүһү!

Ибне Мәсгуддән сорадылар:

- Иң изге гамәл нәрсә?

Ул җавап бирде:

- Иң изге гамәл - вакытында укылган намаз.

Хәзрәти Гали (рг) әйтте: "Җир йөзендәге барча галимнәрдән сорасаң да, шушы җавапны әйтерләр иде, әмма иң изге гамәл - Аллаһ аннан риза булган һәм Аллаһ каршында кабул булган гамәл". Без нәрсә генә эшләсәк тә, нинди генә гыйбадәт кылсак та, Аллаһ ризалыгын өмет итеп, Аллаһ риза булырлык итеп эшләргә тиеш. Шуның өчен дә фарыз намазларны укыр алдыннан һәркайсыбыз нияттә "Халисән лилләһи тәгалә", ягъни "Аллаһ ризалыгы өчен" дип ниятлибез. Аллаһ риза булсын өчен фарызларны үтәү, хәрамнардан тыелу кирәк.

Без җәмгыять эчендә, халыклар арасында яшибез. Аллаһ ризалыгын алу өчен фарызларны үтәү, мәчеткә йөрү генә җитми. Аллаһ Үзенең ризалыгын кешеләр ризалыгы аркылы да җиткерә. Һәркайсыбызның туган ил, туган җир, туган тел, милләт, әти-әни, туганнар, күршеләр, җәмгыятьтәге һәр кеше алдында бурычларыбыз бар. Табигать - Аллаһның гаиләсе, Аллаһ һәркемгә әнисенә караганда да якынрак, шуңа күрә җәмгыять каршындагы бурычларны да үтәргә кирәк. Моның дәлиле булып Галкама сәхабә вакыйгасы тора.

Галкама исемле сәхабә җан бирергә ята икән, ләкин шәһадәт кәлимәсен әйтә алмый. Үзе сәхабә, намазларын да укыган, мәчеткә дә йөргән. Рәсүлуллаһка (сгв) бу турыда әйткәч: "Әнисе бармы?" - дип сораган. Барлыгын белгәч, әнисеннән: "Улыңа рәнҗемәгән идеңме?" - дип сораган. Анасының баласына үпкәсе барлыгын белгәч, бәхиллеген сораган. Бәхиллеген бирмәгән очракта, улының тәмуг утында янасын аңлаткан, шуннан соң әни кеше бәхиллеген биргән. Галкама сәхабә дә шәһадәт кәлимәсен әйтеп, мәңгелеккә үткән.

Кайберәүләр намазга шулкадәр игътибар күрсәткән була, ә шул ук вакытта тирә-юньдәгеләрне, әти-әнине, хәтта аныңча уйламаган дин кардәшен рәнҗетүне бернигә дә санамый. Аллаһның ризалыгын аласың килә икән, фарызларыңны җиренә җиткереп үтәргә тырыш, хәрамнан тыел һәм һәркем белән яхшы мөнәсәбәттә бул, уртак тел тап. Хәтта гөнаһ кылучының да үзе түгел, эшләгән гөнаһы нәфрәт уятырга тиеш. Берәү коега төшеп китсә яисә сазлыкка бата башласа, аны күргән һәркем аңа кулдан килгән кадәр ярдәм итәргә тырыша. Ни өчен соң гөнаһ баткаклыгына кергәннәргә ярдәм кулы сузарга ашыкмыйбыз? Алар да бит Аллаһ бәндәсе, алар да Аллаһка кадерле (бала анасына кадерле булган кебек). Аларны сүгеп, каһәрләп, гайбәтләрен сөйләп кенә Аллаһның ризалыгын алып булырмы икән?

Аллаһ ризалыгын алу өчен кешеләрнең ризалыгын алырга кирәк икәнен түбәндәге хәдис тә аңлата.

Хак Тәгалә хәзрәте Кыямәт көнендә адәм баласына: "И адәм баласы! Мин хаста булдым, син минем хәлемне сорамадың", - диде. Адәм баласы: "И Раббым! Мин синең хәлеңне ничек сорый алам? Син бөтен галәмнәрне тәрбия итүчесең", - дигәч, Аллаһы Тәгалә: "Минем фәлән бәндәм авырый иде, син аның хәлен белмәдең, әгәр белгән булсаң, аның савабын Минем хозурымда тапкан булыр идең", - дияр. Аллаһы Тәгалә: "И адәм баласы, ашар өчен синнән ризык сорадым, син бирмәдең", - дип әйтер. Адәм баласы: "И Раббым, мин сиңа ничек ризык бирим? Син бөтен галәмнәрне тәрбия итүчесең", - дигәч, Аллаһы Тәгалә: "Белмәдеңмени, минем фәлән бәндәм синнән ашарга сорады, син шуны бирмәдең! Әгәр дә аңа ашарга биргән булсаң, аның савабын минем хозурымда тапкан булыр идең!" - дияр. Аллаһы Тәгалә: "И адәм баласы! Эчәр өчен синнән су сорадым, син эчермәдең!" - дип әйтер. Адәм баласы: "И Раббым, мин Сиңа эчәргә ничек бирә алыйм, Син бөтен галәмнәрне тәрбия итүчесең!" - дигәч, Аллаһы Тәгалә: "Фәлән бәндәм синнән эчәргә сорады, шуны эчәргә бирмәдең! Әгәр

# К.НАСЫЙРИ ИҖАТЫНДА ТАТАР ХАЛЫК ТӘРБИЯСЕ



**Татар халкының тәрбия тәҗрибәсен, педагогикасын һәрьяклап тирәнтен өйрәнгән һәм туплаган галим-мәгърифәтче, педагог һәм язучы Каюм Насыйри (1825–1902) халыкны белемле итү, аның телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен үстерүдә зур эш башкара, аң-белемне ана телендә бирүне, укымышлы кеше булу өчен үз телен белүне хуплый.**

К.Насыйри үзе җыйган фольклор әсәрләрен “Кырык бакча” (1880), “Фәвакиһел-җөләса филәдәбият” (1884), “Китаб-әт-тәрбия” (анда 113 нәсихәт тупланган, 1891) китапларында бастыра. Аларда халкыбызның тормыш-көнкүреше, үзара мөнәсәбәте, эчке кичерешләре, тәрбия тәҗрибәсе тасвирлана. Бу һәм башка хезмәтләрендә, укытучылык эшчәнлегендә халыкның педагогик мирасына, тәрбиядә халыкчанлыкка һәм гуманлылыкка зур өстенлек бирә һәм бу аның төп педагогик принцибы булып әверелә. Чөнки ул халык тәрбиясенең кешене белемле һәм әдәп-әхлаклы итеп үстерүгә гаять зур өлеш керткәнен дәлилли, шуңа күрә татар халык педагогикасын һәрьяклап өйрәнүгә күп көч куя. Кыскасы, аның хезмәтләре татар халкының тәрбия тәҗрибәсенә нигезләнеп иҗат ителә.

Мәгърифәтче балаларның тәрбияле, белемле һәм сәламәт булып үсүенә булышуны иң изге эш итеп саный. “Әхлак рисаләсе” дигән китабында, балаларга мөрәҗәгать итеп, болай ди: “И газиз бала!.. Адәмгә бигрәк кирәк вә бигрәк лязем нәрсә – гыйлемдер. Наданлык дигәнемез белмәклеге лязем булган нәрсәне белмәссезлектер. Бу наданлык кешене игътибардан чыгара вә хайван дәрәҗәсенә кертә торган сыйфаттыр. Кайда барса да, надан кешенең кадере юктыр… Гыйлем үгрәнмәгә, укымага, язмага вә һөнәр вә мәгърифәт хасил итмәгә иҗтиһад кыл, чөнки гыйлем вә мәгърифәт иясе һәр йирдә хөрмәтле булып, халык арасында кадере зур булыр”. Гыйлемле булу белән бергә, К.Насыйри яшьләрне һөнәргә өйрәнергә чакыра, вакытлы гына була торган милек-байлык белән мавыгып, кәсеп үзләштерү гамәлен үз итмәсә, киләчәге ышанычсыз булуын искәртә. Бу уңайдан “Китаб-әт-тәрбия”дә ул болай яза: “Әй җаннарым-угланнарым, нәсихәтне ишетегез – һөнәр үгрәнегез. Дөньяның милкене вә дәүләтенә ышанырга ярамас… Һөнәр – бер агым судыр, вә ышанычлы дәүләттер, һөнәр иясе әгәр дәүләттән төшсә дә кайгы юк... Әй угыл, син дә һөнәр үгрән, тәрбия үгрән, гыйлем үгрән (1 нче тәрбия). Әлеге мәсьәләдә ике олы мәгърифәтче фикерләренең тәңгәл килүе, яшьләргә гыйлем-тәрбия бирү өлкәсендә карашларының дөрес педагогик-психологик, фәнни нигездә һәм кысаларда булуын дәлилли. Бу уңайдан К.Д.Ушинский киңәшләре дә бик гыйбрәтле: “Хезмәтегезне дөрес сайлаган һәм аңа бөтен күңелегезне биргән булсагыз, бәхет сезне үзе эзләп табар”. Чыннан да, гадел хезмәт белән эшләп алган дәүләт – бәхет. Моннан кала, үзең яраткан һөнәр – рухи канәгатьләнү, күңел күтәренкелеге чыганагы. Монысы – тагын да олырак бәхет. Мәгърифәтчеләр язганча, “ышанычлы дәүләт” булган шөгыль-кәсепне ничек “дөрес сайлап, бәхетле булырга?” Һөнәрләрнең абруе төрлечә үзгәргән, махсус уку йортын тәмамлаганда һөнәр-белгечлек буенча эшкә урнашу гарантияләнмәгән, кайбер төр һөнәр ияләре арасында эшсезлек күренешләре тарала барган хәзерге чорда, яшьләргә һөнәргә дөрес юнәлеш бирү гаять җаваплы педагогик, психологик, социаль, икътисади, иҗтимагый проблема булып әверелә. Монда яшь кешенең теләк-омтылышын белү генә җитми, бәлки һәрберсенең аерым-аерым сәләт-булдыклылыгын өйрәнү, гаилә белән бергә киңәш-табыш итеп, дөрес юнәлеш бирү беренче адым булып тора.

Тәрбиядә халыкчанлык һәм гуманлылык – К.Насыйриның төп педагогик принцибы. Шушы нигездә аның тәрбия турындагы фикер-карашлары, халык тәрбиясе тәҗрибәсеннән ул туплаган тәгъбир-нәсихәтләр татар халкын, аеруча яшьләрне рухи-әхлакый саф итеп тәрбияләргә, әйләнә-тирәдәге тискәре, җинаятьчел күренешләрдән гыйбрәт ала белергә, “нәфеснең җинаять җитәкчесе” булуын аңларга сәләтле шәхес итеп формалаштырырга ярдәм итәләр. Аларда явызлыкны күрә алмау, аңа нәфрәт, яшьләрне андый гамәлләрдән йолып калу, кешелеклелек, мәрхәмәтлелек тәрбияләү төп максат итеп карала. Ничек булырга кирәклек турында вәгазь уку, үгетләү аның өчен тәрбиядә төп принцип түгел, ул яманны һәм яхшыны, явызлыкны һәм тәүфыйклылыкны, нәфесне һәм чик-чаманы, уртачалыкны янәшә куеп, чагыштырып төшенергә ярдәм итә. Бу уңайдан аның “Китаб-әт-тәрбия” дигән хезмәте – аеруча кыйммәт һәм бай чыганак. Ул һәр тәрбияче-укытучының, ата-ананың өстәл китабы булырга хаклы. 112 нче тәрбиядә болай диелә: “Әй угыл, дүрт нәрсә бардыр ки, адәм аны ифрат вә чиктән тыш күп кыйлса, һәлак буладыр: әүвәл хатын белән маташса, адәм һәлак буладыр. Янә явызлык артыннан күп йөри торгач, адәм һәлак буладыр. Дәхи күп отыш уйнаса, адәмнең һәлакәте андадыр. Дәхи дә күп хәмер эчсә, һәлак булмай калмайдыр”.

59 нчы тәрбиядә болай диелә: “Хәерле мал шулдыр: хәләлдән килеп, изге юлга сарыф кылыныр. Хәерсез мал шулдыр: хәрамнан килеп, начарлык һәм әшәкелекләр юлына сарыф кылыныр”. 75 нче тәрбия дә алдагысы белән аваздаш: “Әй угыл, мал табуның юллары күптер. Нинди генә юл булмасын, малны хәләлдән табу фарыздыр. Хәләлдән килгән мал – тотрыклы буладыр. Хәрам мал тиз кулыңнан китәр, җаваплылыгы һәм авырлыклары гына сиңа калыр”. Бу нәсихәтләрнең нигезендә бик мәгънәле һәм кисәтүле фикерләр ята. Әйтик, анда хәрам мал өчен җаваплылык һәм авырлыклар сиңа калыр, диелә. Бу сүзләрнең мәгънәсен нечкәләп барлый белү бик әһәмиятле. Чөнки хәрам юл белән табылган мал өчен кеше иртәме-соңмы Аллаһ алдында җавап тотарга тиеш һәм нәсихәт андый затның җинаятенә туры килердәй авырлыкларның котылгысыз булуын искәртә. Әлеге нәсихәтләрне тәрбия эшендә файдаланганда истә тотардай тагын бер үзенчәлек турында искәртү кирәктер. Хәзерге чор балаларына хәләл һәм хәрам төшенчәләренең мәгънәсен ачыклау шарт булып тора. Чөнки алар еш кына көндәлек эш-гамәлләрендә бу һәм рәнҗеш, гөнаһ, тәүбә кебек әдәп-әхлак категорияләре буенча яшәү түгел, аларның асыл мәгънәсен дә белмиләр. Бу тема буенча тәрбия эшен оештыру юнәлешендә тәкъдимнәрне дәвам итеп булыр иде. Ләкин монда бер киңәш белән генә дә чикләнергә була. Эш шунда ки, “Татар халык педагогикасы”нда (XI сыйныф, “Мәгариф” нәшрияты, 2000) әлеге проблемага багышлап “Хәләл һәм хәрамга исламның карашы” дигән тема бирелгән. Алда сүз барган нәсихәтләр буенча алга таба эшне шушы чыганактан файдаланып башкарырга була.

К.Насыйриның "Тәрбия китабы"ндагы тагын бер балалар һәм яшьләр өчен бик гыйбрәтле нәсихәткә тукталыйк. Чөнки мондый тәрбия еш кына аерым кешеләрдәге әшәке теллелек киң таралган, сөйләмдә оятсыз, сүгенү сүзләре еш кулланылган хәзерге чорда аеруча тансык. 89 нчы тәрбиядә болай диелә: "Әй угыл, кешенең күңеленә хилаф килә торган сүзне телеңә китермә. Бер сүзне син пәйвайсыз әйтеп җибәрерсең, ишеткән кешенең күңеле җәрәхәтләнә торган сүз булыр, күңеле рәнҗер. Кеше күңелен рәнҗетүдән бик саклан".

Халкыбызның "Тел белән төенләгәнне теш белән дә чишә алмассың", "Авыз белән бәйләгәнне кул белән чишә алмассың" кебек тәгъбирләрендә дә әлеге нәсихәттәге кебек мәгънә аңлашыла. "Әйткән сүз аткан ук" дигәндәй, кешенең бәгыренә тия торган сүзне ычкындырсаң, аны кулың, тешең белән дә төзәтә алмыйсың. "Кеше күңеле - пыяла, бер ватылса, төзәлер дип уйлама", - ди татар халкы.

К.Насыйри нәсихәте буенча тәрбия эшен кешене рәнҗетү, күңел рәнҗү төшенчәләренең асылмәгънәсен ачыклаудан башлау зарурилыгы үзеннән-үзе аңлашыла. Нәрсә ул рәнҗеш, кешенең рәнҗүе нинди халәт ул? Чөнки сүзнең мәгънәсенә төшенмәгән килеш, тыңлаучылар белән аның тирәли сүз куерту буш сүзлелек кенә түгел, шагыйрь әйтмешли, "тел зинасы" да була.

**(Ахыры киләсе санда.)**

***Шамил ҖӘЛӘЛИЕВ,***
***педагогика фәннәре кандидаты,***
***К.Насыйри премиясе лауреаты***

# БУЛСЫН ДИСӘҢ

дә аңа эчәргә биргән булсаң, аның савабын минем хозурымда тапкан булыр идең!" - дияр.

Бирүче түгел, сорап килүче Аллаһның рәхмәтен китерүче.

Гобәйдулла Ахрар ач килеш базар буйлап барганда, аңа бер кеше килеп: "Бик тә ачыктым, ашарга бирә алмассыңмы?" - дип мөрәҗәгать итә. Гобәйдулла Ахрар янәшәдәге ашханәгә кереп, үзенең чалмасын тәкъдим итә: "Чалмам чиста, аны табак-савыт яисә өстәл сөртергә куллана аласыз, чалмамны алыгыз һәм шул хисаплык бу кешенең тамагын туйдырыгыз", - дип үтенә, гәрчә үзе ач булса да. Аллаһ Раббыбыз аңа алдагы тормышында әүлиялек һәм бик күп байлык бирә. Ул күп байлык хуҗасы булгач та башкаларга хезмәт итүдән туктамый.

Безгә кем аркылы Аллаһның рәхмәте килә - без белмибез, һәркемгә игътибарлы һәм ихтирамлы булу кирәк.

Намаз укымауларын сәбәп итеп, әти-әнисе, туганнары белән араларын өзгән кешеләргә Ибраһим галәйһиссәлам вакыйгасын сөйләп үтмәкче булам.

Ибраһимга (гс) бер кеше килә һәм ашарга сорый. Ибраһим (гс) аның утка табынучы икәнен белгәч, ашарга бирми чыгарып җибәрә. Аллаһ Раббыбыз: "Мин җир йөзендә бар халыкка диненә, милләтенә карамыйча ризык бирәм, син нишләп минем бәндәмне борып чыгардың", - дип шелтәли. Ибраһим (гс) урамга чыгып теге кешене куып җитә һәм өенә чакырып кунак итә. Әлеге кеше: "Нишләп әле синең фикерең үзгәрде?" - дип сорый. Ибраһим (гс) Аллаһның шелтәләве турында әйтә. Әлеге кеше: "Мин синең Раббыңа иман китерәм", - ди. Иман китергәнбез икән, намаз укыйбыз икән, безнең үз-үзебезне тотышыбызда, холкыбызда аның әсәре булырга тиеш. Кешеләр безгә карап ислам диненә бәя бирә. Башкаларга карата тискәре мөнәсәбәттә булсак, үзебезне матур тота алмасак, башкалар аны диннең кимчелеге дип кабул итә һәм ул аларны диннән ерагайта. Бу очракта без телибезме-теләмибезме, кешеләргә Аллаһның рәхмәтен җиткерүче түгел, диннән биздерүче ролен үтибез.

Аллаһ Раббыбыз бар кешене дә бер төрле итеп яратмаган, бар кеше дә берьюлы дингә дә килми. Кайчандыр үзебезнең дә намазсыз йөргән, ураза тотмаган вакытлар бар иде. Хәзер шуларны сәбәп итеп ара өзү, дошманлык саклау - Аллаһ ризалыгын алу түгел. Күркәм холкың, матур мөгамәләң белән кемдәдер дингә мәхәббәт уята алгансың икән, Аллаһның ризалыгын алдың дигән сүз. Вәгазь ничек кенә матур булмасын, әгәр дә аның артында гүзәл әхлаклы кеше тормаса, ул - буш сүз. Үз сүзең белән үзеңне тәртипкә китерә алмыйсың икән, сүзеңнең куәте башкаларга ничек ирешсен?.. Чиста калебтән чыккан сүзнең генә куәте бар.

Бөек татар шагыйре Г.Тукай: "Әйдә, халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә", - дип язган.

Аллаһ ризалыгын аласың килә икән, ризыгыңны да хезмәт белән тап, башкаларга да хезмәт ит.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) дә: "Халыкка хезмәт иткән генә халыкның хөрмәтен казана ала һәм Аллаһ каршында дәрәҗәгә ирешә", - дигән. Шәех Мәгъруф Кархи янына бик карт, зәгыйфь бер кеше килә. Шәех аны урын җәеп яткыра һәм үзе тәрбияли башлый. Авыру саташып, ыңгырашып, каты кычкырып берәүгә дә йокларга ирек бирми. Моңа чыдый алмыйча, өйдә булганнар кайсы кая таралып бетә, шәех белән хатыны гына кала. М.Кархи бернигә карамыйча, авыруны тәрбияләүне дәвам иттерә. Авыру да үзенә булган игътибарга ияләнә һәм шулай тиеш дип кабул итә башлый.

Көннәрдән бер көнне авыру янында утырган шәех йоклап китә. Әлеге авыру аның йоклап утырганын күргәч: "Бу нинди әүлия инде, тиешенчә хезмәт тә күрсәтә алмый, моның тышкы ягы гына әүлия, эче тулы пычрак икән. Авыру кешене кайгыртасы урынга, тамагын туйдыра да, йоклап утыра", - дип кычкыра башлый.

Мәгъруф Кархиның хатыны бу сүзләрне ишетеп: "Әнә, ул синең турыда ниләр сөйли, аны куып чыгар, бу - яхшылыкның кадерен белми торган юньсез икән", - ди. Аңа каршы М.Кархи: "Әй хатыным, ник үпкәлисең, ул сине түгел, мине сүкте бит. Күрмисеңмени, ул авырый, хәле җиңел түгел, йоклый да алмый. Аңла, Аллаһ ризалыгы килә торган хакыйкый изгелек - ул кешеләргә килгән борчу-мәшәкать, кыенлыкларны уртаклашу", - дип җавап бирә.

Башкаларга килгән авырлыкларны уртаклашу - сәламәтлегеңә шөкрана һәм Аллаһның ризалыгын алуга сәбәп булып тора. Пәйгамбәребез (сгв): "Кешеләрнең моңзарларын сөйләп сезгә мөрәҗәгать итүләре - Аллаһ рәхмәте килүгә бер мисал", - дигән.

Аллаһ синнән риза икән, синең йөрәгеңдә Аллаһка мәхәббәт булырга тиеш һәм ул йөрәк һәркемгә ярдәмгә ашыгып торырга тиеш. Шул чакта гына син ихласлы мөселман булырсың. Шул вакытта гына синең белән бергә исемең үлмәячәк. Ихластан башкаларга ярдәм иткән, башкаларның борчу-мәшәкатьләрен, кайгы-хәсрәтләрен уртаклашкан, гомерен халкына хезмәткә багышлаган кеше Аллаһның ризалыгын ала һәм үлгәннән соң да башкаларның күңелендә яши.

Телләребезгә, күңелләребезгә сабырлык биреп, алдагы гомерләребезне үзеңә риза булырлык итеп үткәрергә насыйп кылсаң иде, Раббым!

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые**



# СКОПЬЕДА КАР МӘЧЕТ БАРЛЫККА КИЛДЕ

**Сирәк була торган мөмкинлекне - карның аномаль күплегеннән файдаланып, Македония башкаласының иң яшь мөселманнары кар әвәләп мәчет ясады, дип хәбәр итә www.regions.ru сайты.**

Ерактан чып-чын мәчет кебек күренеп торган кар "бина"ның биеклеге ике метрлап чамасы һәм мәчет әйләнәсе бер-берсенә ныгытып тартылган кара тасмалы кар баганалар белән әйләндереп алынган.

Мәчет хәйрия максатыннан - авыру балага дәваланырга иганә җыю өчен төзелгән. Яшь төзүчеләр кар сарае белән янәшә генә акча җыю өчен әрҗә дә куйганнар, алар аны хәзер саклап тора.

Мондый акция ясау инициативасы балалардан булганлыкны Македония Республикасының Ислам берләшмәсе биргән аңлатмалар да раслый. Аның вәкилләре кардан эшләнгән мәчет турында ишеткән, әмма алар аңа җитди карамыйлар. "Бу балаларның эше һәм аңа нинди дә булса мәгънә бирергә кирәкми. Балаларның мондый бина әвәләп ясаулары бик тә тәэсирле, дулкынландыргыч, уйланландыра торган күренеш", - дип белдерде мөселман оешмасының матбугат сәркатибе Абас Ислами.

Шунысын да билгеләп үтик: 2013 елның кышында Швециядә боздан төзелгән мәчет ачылыр дип көтелә; ул боздан эшләнгән билгеле Icehotel отеле янында булачак (Лапландиянең Юккасъярви авылы).

Отель әйләнәсендә һәр елны боздан төзелеп киленгән чиркәүдә елның-елында йөз илледән пар никахлашкан. Шуның белән рухланып, мөселманнарның швед ассоциациясе имамы Мәхмүд Әлдәбә мөселманнарга да боздан гыйбадәтханә кору тәкъдиме белән чыкты. Аның фикеренчә, гадәти булмаган мәчет төзелеше төрле мәдәният һәм диннәр белән диалогны җайга салырга ярдәм итәчәк.

**Нияз САБИРҖАНОВ**

# Зур югалту



Милли мәдәниятебез, театр сәнгате зур югалтуга дучар булды. 2012 елның 26 февралендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының директоры Шамил Зиннур улы Закиров кинәт арабыздан китте.

Шамил Закиров 40 елдан артык республикабызның мәдәнияте һәм сәнгате өлкәсендә хезмәт итте.

Ул 1945 елның 15 мартында Татарстанның Чистай районы Нарат-Елга авылында дөньяга килә. 1970 елда Казан химия-технология институтын, 1972 елда Ленинград дәүләт мәдәният институтының аспирантурасын тәмамлый. 1979 елдан 1985 елга кадәр Чаллы шәһәрендә "Энергетик" мәдәният сараеның директоры, бер үк вакытта 1982 елдан шәһәр советында мәдәният бүлеге мөдире булып эшли.

1985 елның 4 февраленнән Шамил Зиннур улы Закиров Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры итеп билгеләнә. Ул үзенең эшчәнлеген илебездәге катлаулы үзгәртеп корулар чорында һәм театр яңа бинага күчәргә әзерләнгәндә башлады. Беренче адымнарыннан ук бу вазифада талантлы җитәкче, профессионал һәм дистәләгән яңа игелекле изге эшләр башлап җибәрүче тынгысыз иҗади шәхес буларак танытты. Шамил Закиров җитәкчелегендә театр дөньякүләм мәйданга чыкты: Мәскәү, Санкт-Петербург, Латвия, Төркия, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Германия, Финляндия, Бөекбритания, Колумбиядә уздырылган гастроль-фестивальләрдә катнашып, зур уңыш казанды. Бөтен дөнья театрлары өчен зур вакыйгага әйләнгән "Нәүрүз" төрки халыклар театр фестиваленең Казанда төпләнүе дә Г.Камал театры җитәкчелеге тырышлыгы белән тормышка ашты.

Шамил Зиннур улы яшь кадрлар әзерләү буенча да зур эш башкарды. 1990 елда Казан мәдәният һәм сәнгать университетында аның ярдәме белән драма актёрлары бүлеге ачылды. Ул үзе дә бу югары уку йортында озак еллар дәвамында доцент булып эшләде. "Һөнәр" яшь татар режиссурасы фестиваленең барлыкка килүендә һәм аның уңышлы дәвам итүендә дә Ш.З.Закировның өлеше гаять зур.

Республика күләмендә уздырыла торган һәм традициягә әйләнгән "Сәйдәшстанга сәяхәт", "Исхакый укулары" һ.б. шуның кебек зур мәдәни чараларның чишмә башында да Шамил Закиров торды. 2003 елда Ш.З.Закиров инициативасы белән милли драматургияне һәм театр сәнгатен үстерү максатында "Яңа татар пьесасы" конкурсы оештырылды.

Ш.З.Закиров татар дөньясы мәнфәгатьләрен ихлас күңелдән кайгырткан чын милләтпәрвәр шәхес, халкыбызның фидакарь улы иде. Ул һәркемгә аталарча киңәш бирүче, ярдәмчел, кайгыртучан остаз булды.

"Шамил Зиннур улының арабыздан китүе - татар театры өчен генә түгел, бөтен татар халкы, милләтебез һәм динебез өчен зур югалту. Ул һәрбарчабызның да күңеленә олы йөрәкле, ихлас, милләт өчен җан атып яшәүче чын кеше буларак кереп калды, үзенең тыйнаклыгы һәм сабырлыгы белән күпләргә үрнәк була белде, - диелә ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз уртаклашкан кайгынамәдә. - Аллаһы Тәгалә Шамил Зиннур улының туганнарына, хезмәттәшләренә сабырлыклар насыйп әйләсә иде. Татар халкын мондый зур югалтулардан, бәла-казалардан сакласа иде".

# РИУда - Дистанцион белем бирү үзәге

**Россия ислам университетында Дистанцион белем бирү үзәге ачыла. Үзәкне РИУ мөгаллиме, программист Илшат Нәҗипов җитәкли.**

Яңа үзәкнең максаты - белем бирү процессында дистанцион технологияләрне куллану. Бу бигрәк тә читтән торып белем алучы студентлар өчен кулай. Ул сессияләр арасында өстәмә белем алырга мөмкинлек бирәчәк. Чөнки студентлар сессияләрнең кыска вакытлы булуы сәбәпле, аның дини белем алу өчен җитәрлек булмавын искәртә.

Укулар Интернет аша Sakai системасын кулланып алып барылачак. Әлеге система Россиядә бик нык таралыш тапмаган, әмма Европаның әйдәп баручы университетлары аны куллана. Дистанцион технологияләр ярдәмендә студентлар консультацияләр генә алып калмаячак, ә имтиханнар да тапшыра алачак.

Март аеннан РИУда университет укытучылары өчен курслар башланачак. Алар әлеге программа ярдәмендә дистанцион белем бирү өчен электрон уку әсбаплары эшләргә өйрәнәчәк.

Университет җитәкчелеге алга таба дистанцион белем алуга күбрәк җәлеп ителәчәк экспериментал төркемнәр оештырырга ниятли. Бу, үз чиратында, сессияләр вакытында РИУ тулай торакларын бераз бушатырга мөмкинлек бирәчәк, дип хәбәр итә университетның матбугат хезмәте.

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 3.03.12 | 5:59 | 7:29 | 13:02 | 16:36 | 18:23 | 19:53 |
| *Якшәмбе* | 4.02.12 | 5:57 | 7:27 | 13:02 | 16:37 | 18:25 | 19:55 |
| *Дүшәмбе* | 5.02.12 | 5:54 | 7:24 | 13:02 | 16:39 | 18:27 | 19:57 |
| *Сишәмбе* | 6.02.12 | 5:52 | 7:22 | 13:02 | 16:40 | 18:29 | 19:59 |
| *Чәршәмбе* | 7.02.12 | 5:49 | 7:19 | 13:02 | 16:41 | 18:31 | 20:01 |
| *Пәнҗешәмбе* | 8.03.12 | 5:46 | 7:16 | 13:02 | 16:43 | 18:33 | 20:03 |
| *Җомга* | 9.03.12 | 5:44 | 7:14 | 13:02 | 16:44 | 18:35 | 20:05 |
| *Шимбә* | 10.03.12 | 5:41 | 7:11 | 13:02 | 16:45 | 18:37 | 20:07 |

# "Гарәп язы" һәм интернет-технологияләр турында Путинниләр яза?

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Вакыйгалар барышында һаман да ешрак "мягкая сила" кебек төшенчә очрый, ул - корал кулланмыйча, ә бәлки информацион һәм йогынты ясауның башка чаралары хисабына тышкы сәяси максатлар өчен инструмент һәм методлар җыелмасы. Кызганыч, сирәк түгел генә мондый методлар экстремизмга, сепаратизмга, милләтчелеккә әйләндерү һәм коткы тарату, иҗтимагый аң белән хәйләләү, суверен дәүләтләрнең эчке сәясәтенә турыдан-туры тыкшыну өчен кулланыла", - дип билгеләп уза Россия премьеры.

Гарәп дөньясындагы процессларның икътисади ягына кагылып, Владимир Путин шул фактларга да игътибар итә: турыдан-туры "гарәп язы" аша узган илләр, элегрәк Гыйрактагы шикелле, Россия компанияләре җирле базарларда уннарча еллар эшләмәгән позицияләрен югалта, шактый зур коммерцияле контрактлардан колак кага. Ә бушап калган куышлар идарә итүче режимга алмашка кул куйган дәүләтләрнең икътисади операторлары белән тула.

"Шундый фикер туарга мөмкин: трагик вакыйгалар үзләре билгеле бер дәрәҗәдә кеше хокуклары турында кайгырту өчен җайлаштырылмаган булды, бу - базарларны яңадан бүлешүгә кемнеңдер кызыксынуы аркасында. Ничек кенә булган булса да, безгә, әлбәттә, боларның барысына да "олимпийский" тынычлык белән карап торырга ярамый. Һәм без гарәп илләренең яңа властьлары белән актив эшләргә ниятлибез", - дип ассызыклый премьер-министр.

Владимир Путин, Россия, Исламда урталыкны тотучы вәкилләр белән һәрвакытта да яхшы мөнәсәбәтләрдә торганлыкны билгеләп, дөньяга карашлары илебез мөселманнары традицияләренә якын торган ил лидерлары белән элемтәләрне арттырырга әзер булуын җиткерде. "Без барлык гарәп илләре белән дә сәясәт һәм сәүдә-икътисад элемтәләрен активлаштырырга уйлыйбыз, шул исәптән, кабатлап әйтәм, турыдан-туры ил эче һәлакәт кичергәннәре белән дә. Моннан тыш, Россиянең тулысынча Якын Көнчыгыш аренасында үзенең әйдәп баручы позицияләрен саклавында чын алшартлар күрәм", - диде Россия премьеры.

Россия дипломатиясе, В.Путин ассызыклаганча, гарәп-Израиль мөнәсәбәтләрендә татулык кабат торгызылсын өчен актив булышлыгын дәвам иттерәчәк. Бу ике яклы нигездә һәм Гарәп илләре лигасы (ЛАГ) белән адымнарны координацияләү барышындагы Якын Көнчыгыш "квартет"ы форматында тормышка ашырылачак.

***Нияз САБИРҖАНОВ***

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №9 (126) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-527.

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 1 март көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллanудан сакланыгыз!**